**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

24.01.2025 № 50

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татарстан Республикасы судьялары квалификация коллегиясендә җәмәгать вәкиллегенә кандидатларны алдан сайлап алу комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татарстан Республикасы судьялары квалификация коллегиясендә җәмәгать вәкиллегенә кандидатларны алдан сайлап алу комиссиясе төзү турында» 2002 елның 22 октябрендәге 66 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 18 октябрендәге 195 номерлы, 2006 елның 20 ноябрендәге 282 номерлы, 2008 елның 16 октябрендәге 264 номерлы, 2010 елның 13 августындагы 263 номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 24 маендагы 235 номерлы, 2015 елның 14 февралендәге 129 номерлы, 2016 елның 24 ноябрендәге 681 номерлы, 2017 елның 21 августындагы 511 номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 20 ноябрендәге ПУ-768 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 12 апрелендәге 147 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татарстан Республикасы судьялары квалификация коллегиясендә җәмәгать вәкиллегенә кандидатларны алдан сайлап алу комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан Ш.Ш. Яһудинны чыгарырга;

Комиссия составына Чубаров Александр Анатольевичны – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисен (килешү буенча) кертергә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ